**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1071

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1042 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1042 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнарда «җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җәмгыяте» сүзләрен перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнарда «җаваплылыгы чикләнгән «Диализ клиникасы» җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2016 елга гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга күрсәтә торган амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күләмнәре нормативларында:

«җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җәмгыяте» сүзләрен «җаваплылыгы чикләнгән «Диализ клиникасы» җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

«Перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтү» бүлегенең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, шул исәптән:<br>2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 15 августына кадәр<br>2016 елның 16 августыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр | пациент | <br><br><br><br>1<br><br>2». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1071.doc